**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2901**
**07.06.2019**

Башкарма комитетның аерым карарлары үз көчен югалтуны тану турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм «Россия Федерациясе бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» Федераль законның 3 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 18 июлендәге 178-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Субсидияләр рәвешендә, шул исәптән конкурс нигезендә бирелә торган грантлар бирү тәртибен билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 2010 елның 27 мартындагы 322 нче карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Физик затларга күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең гомумроссия база (тармак) исемлекләрен (классификаторларын) һәм физик затларга күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләренең федераль исемлекләрен һәм күрсәтү һәм башкару Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында каралган эшләр исемлекләрен формалаштыру, алып бару һәм раслау турында» 2017 елның 30 августындагы 1043 нче карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) 2014 елның 19 мартында «Челнинские известия» газетасының 20 нче санында басылып чыккан Башкарма комитетның «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга грантлар бирү тәртибе турында нигезнамәне раслау хакында» 2014 елның 13 мартындагы 1460 нчы карары;

2) 2015 елның 7 октябрендә «Челнинские известия» газетасының 73 нче санында басылып чыккан Башкарма комитетның «Яр Чаллы

шәһәренең муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган муниципаль хезмәтләр һәм эшләр исемлеген формалаштыру, алып бару һәм раслау тәртибе турында нигезнамәне раслау хакында» 2015 елның 22 сентябрендәге 5382 нче карары.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин